ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2022 елның 26 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда «№ 83 (I өлеш)» сүзләреннән соң «$29^3$ статьяның 2 һәм 3 пунктларының («Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 448-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 36 – 38 өлешләре нигезендә бирелә торган махсус казна кредитларына карата),» сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяда:
а) 2 өлештә «бюджет ассигнованиеләре суммасына» сүзләреннән соң «, махсус казна кредитлары суммасына» сүзләрен өстәргә;
б) 3 өлештә «югарырак булмаган суммага» сүзләреннән соң «, махсус казна кредитлары суммасына» сүзләрен өстәргә;

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 апрель
№ 20-ТРЗ